# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**13 ноябрь 2020 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Нарат-Асты авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Нарат-Асты авылы урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Нарат-Асты авылы җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары,трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Нарат-Асты авылы өчен газонокосилка (Тремер) сатып алу.

3. Әлеге карарны Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Хадиуллин